**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об образовании Республиканского координационного комитета по проведению в Республике Татарстан Десятилетия науки и технологий

В целях координации проведения в Республике Татарстан Десятилетия науки и технологий в соответствии с Указом Президента Российской Федерации от 25 апреля 2022 года № 231 **постановляю:**

1. Образовать Республиканский координационный комитет по проведению в Республике Татарстан Десятилетия науки и технологий.

2. Утвердить Положение о Республиканском координационном комитете по проведению в Республике Татарстан Десятилетия науки и технологий (приложение № 1) и его состав (приложение № 2).

3. Кабинету Министров Республики Татарстан в трехмесячный срок разработать с учетом предложений Республиканского координационного комитета по проведению в Республике Татарстан Десятилетия науки и технологий и утвердить план мероприятий по проведению в Республике Татарстан Десятилетия науки и технологий, а также обеспечить контроль за его реализацией.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
10 ноября 2022 года
№ УП-796

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «10» ноября 2022 года

№ УП-796

**Положение**
**о Республиканском координационном комитете по проведению в Республике Татарстан Десятилетия науки и технологий**

1. Республиканский координационный комитет по проведению в Республике Татарстан Десятилетия науки и технологий (далее – Республиканский координационный комитет) является постоянно действующим коллегиальным органом, образованным для обеспечения взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления), научных, образовательных и иных организаций, общественных объединений, участвующих в подготовке и проведении в 2022–2031 годах Десятилетия науки и технологий.

2. Республиканский координационный комитет в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

3. Основными задачами Республиканского координационного комитета являются:

а) координация деятельности органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, научных, образовательных и иных организаций, общественных объединений по вопросам подготовки и проведения Десятилетия науки и технологий;

б) подготовка, а также координация процессов реализации проектов и мероприятий, направленных на популяризацию научного познания и привлечение талантливой молодежи в сферу исследований и разработок;

в) подготовка, а также координация процессов реализации проектов и мероприятий, содействующих вовлечению научных работников в решение важнейших задач общественно-политического и социально-экономического развития Республики Татарстан;

г) повышение доступности информации о достижениях и перспективах развития сферы науки и технологий для жителей Республики Татарстан.

4. Республиканский координационный комитет осуществляет следующие функции:

а) вносит предложения по формированию плана мероприятий по проведению в Республике Татарстан Десятилетия науки и технологий и определению показателей результативности его реализации;

б) осуществляет координацию деятельности по проведению Десятилетия науки и технологий;

в) рассматривает ежегодные отчеты о ходе реализации плана мероприятий по проведению в Республике Татарстан Десятилетия науки и технологий;

г) осуществляет другие функции, связанные с проведением Десятилетия науки и технологий.

5. Республиканский координационный комитет для решения возложенных на него задач имеет право:

а) направлять Президенту Республики Татарстан и в Кабинет Министров Республики Татарстан предложения и рекомендации по вопросам проведения Десятилетия науки и технологий, а также по вопросам реализации и совершенствования нормативных правовых и организационных основ государственной научно-технической политики Республики Татарстан в целях проведения Десятилетия науки и технологий;

б) запрашивать и получать в установленном порядке от территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, научных, образовательных и иных организаций информацию и материалы по вопросам, относящимся к компетенции Республиканского координационного комитета;

в) создавать рабочие группы по вопросам, относящимся к компетенции Республиканского координационного комитета;

г) приглашать на свои заседания и заслушивать на них представителей территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, научных, образовательных и иных организаций, общественных объединений;

д) привлекать коммерческие и некоммерческие организации для участия в мероприятиях и проектах, реализуемых в рамках Десятилетия науки и технологий;

е) привлекать средства из внебюджетных источников для финансирования мероприятий и проектов, реализуемых в рамках Десятилетия науки и технологий.

6. Состав Республиканского координационного комитета утверждается Президентом Республики Татарстан.

7. В состав Республиканского координационного комитета входят сопредседатели, секретарь и иные члены Республиканского координационного комитета, которые принимают участие в его работе на общественных началах.

8. Сопредседатели Республиканского координационного комитета:

а) руководят работой Республиканского координационного комитета, определяют перечень, сроки и порядок рассмотрения вопросов на заседаниях Республиканского координационного комитета;

б) распределяют полномочия (обязанности) между членами Республиканского координационного комитета;

в) определяют и утверждают повестку дня, дату, время и место проведения заседаний;

г) подписывают протоколы заседаний и другие документы Республиканского координационного комитета.

9. Секретарь Республиканского координационного комитета:

а) участвует лично в заседаниях Республиканского координационного комитета;

б) уведомляет членов Республиканского координационного комитета о месте, дате, времени проведения заседания не менее чем за пять дней до дня проведения заседания, рассылает повестку дня заседания;

в) осуществляет подготовку протоколов заседаний и других документов Республиканского координационного комитета.

10. Члены Республиканского координационного комитета:

а) участвуют лично в заседаниях Республиканского координационного комитета;

б) выносят на обсуждение предложения по вопросам, находящимся в компетенции Республиканского координационного комитета;

в) осуществляют иные мероприятия по подготовке, исполнению решений Республиканского координационного комитета.

11. Заседания Республиканского координационного комитета проводятся в очной или заочной форме по мере необходимости, но не реже одного раза в год.

12. Заседания Республиканского координационного комитета ведут сопредседатели либо один из сопредседателей.

13. Заседание Республиканского координационного комитета считается правомочным, если в нем принимают участие более половины его членов. Решение Республиканского координационного комитета считается принятым, если за него проголосовало не менее половины членов, присутствующих на заседании. По результатам рассмотрения вопросов повестки дня и голосования на заседании Республиканского координационного комитета принимаются решения, которые оформляются протоколом. Протокол заседания Республиканского координационного комитета подписывается сопредседателями либо одним из сопредседателей.

14. Решения, принимаемые Республиканским координационным комитетом, доводятся до заинтересованных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений, иных заинтересованных лиц для руководства при осуществлении текущей деятельности.

15. На основании решений Республиканского координационного комитета могут разрабатываться проекты нормативных правовых актов Президента Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан, а также органов исполнительной власти Республики Татарстан.

16. Организационно-техническое сопровождение деятельности Республиканского координационного комитета осуществляет Аппарат Кабинета Министров Республики Татарстан.

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «10» ноября 2022 года

№ УП-796

**Состав**
**Республиканского координационного комитета по проведению**
**в Республике Татарстан Десятилетия науки и технологий**

| | |
|---|---|
| Фазлеева Лейла Ринатовна | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, сопредседатель Республиканского координационного комитета |
| Гильмутдинов Альберт Харисович | помощник Президента Республики Татарстан, сопредседатель Республиканского координационного комитета |
| Хадиуллин Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан, секретарь Республиканского координационного комитета |
| Абдуллазянов Эдвард Юнусович | ректор федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский государственный энергетический университет» (по согласованию) |
| Айдельдинов Айнур Тауфикович | директор некоммерческой организации «Инвестиционно-венчурный фонд Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Алибаев Тимур Лазович | исполняющий обязанности ректора федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский национальный исследовательский технический университет им. А.Н. Туполева-КАИ» (по согласованию) |
| Ахметова Аделя Маратовна | исполняющий обязанности исполнительного директора автономной некоммерческой организации «Казанский открытый университет талантов 2.0» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Дьяконов<br>Александр Анатольевич | ректор государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Альметьевский государственный нефтяной институт» (по согласованию) |
| Зарипов<br>Айрат Ринатович | председатель Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по образованию, культуре, науке и национальным вопросам (по согласованию) |
| Казаков<br>Юрий Михайлович | временно исполняющий обязанности ректора федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский национальный исследовательский технологический университет» (по согласованию) |
| Калачев<br>Алексей Алексеевич | директор федерального государственного бюджетного учреждения науки «Федеральный исследовательский центр «Казанский научный центр Российской академии наук» (по согласованию) |
| Когогин<br>Сергей Анатольевич | генеральный директор публичного акционерного общества «КАМАЗ» (по согласованию) |
| Коробченко<br>Олег Владимирович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан |
| Маганов<br>Наиль Ульфатович | генеральный директор публичного акционерного общества «Татнефть» имени В.Д. Шашина (по согласованию) |
| Минниханов<br>Рифкат Нургалиевич | председатель Совета Ассоциации содействия цифровому развитию (по согласованию) |
| Нурутдинов<br>Айрат Рафкатович | генеральный директор публичного акционерного общества «Таттелеком» (по согласованию) |
| Ризванов<br>Ирек Асафович | начальник Управления образования Исполнительного комитета муниципального образования города Казани (по согласованию) |
| Салахов<br>Мякзюм Халимулович | президент государственного научного бюджетного учреждения «Академия наук Республики Татарстан» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Салимгараев Айдар Саитгараевич | руководитель Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» |
| Сафин Диас Нургалиевич | генеральный директор закрытого акционерного общества «Инновационно-производственный Технопарк «Идея» (по согласованию) |
| Сафин Ленар Ринатович | ректор федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет» (по согласованию) |
| Созинов Алексей Станиславович | ректор федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский государственный медицинский университет» Министерства здравоохранения Российской Федерации (по согласованию) |
| Сулейманов Тимур Джавдетович | министр по делам молодежи Республики Татарстан |
| Тормасов Александр Геннадьевич | ректор автономной некоммерческой организации высшего образования «Университет Иннополис» (по согласованию) |
| Хайруллин Айрат Ринатович | министр цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан |
| Яруллин Рафинат Саматович | генеральный директор акционерного общества «Татнефтехиминвест-холдинг» (по согласованию) |

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча республика координация комитетын төзү турында

Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 25 апрелендәге 231 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрүне координацияләү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча республика координация комитетын төзергә.

2. Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча республика координация комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча республика координация комитеты тәкъдимнәрен исәпкә алып, өч ай эчендә Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү турында чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 10 ноябрь
№ ПУ-796

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «10» ноябрендәге
ПУ-796 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча республика координация комитеты турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча республика координация комитеты (алга таба – Республика координация комитеты) 2022–2031 елларда Фән һәм технологияләр унъеллыгын әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашучы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнары), фән, мәгариф һәм башка оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү өчен төзелгән даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

2. Республика координация комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Республика координация комитетының төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, фән, мәгариф һәм башка оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең Фән һәм технологияләр унъеллыгы чараларын әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча эшчәнлеген координацияләү;

б) фәнни белемне популярлаштыруга һәм талантлы яшьләрне тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсенә җәлеп итүгә юнәлтелгән проектларны һәм чараларны әзерләү һәм аларны гамәлгә ашыру процессларын координацияләү;

в) Татарстан Республикасының иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисадый үсеше мөһим бурычларын хәл итүгә фәнни хезмәткәрләрне тартуга ярдәм итә торган проектлар һәм чаралар әзерләү һәм аларны гамәлгә ашыру процессларын координацияләү;

г) Татарстан Республикасында яшәүчеләр өчен фән һәм технология өлкәсе казанышлары һәм үсеш перспективалары турындагы мәгълүматның ачыклыгын арттыру.

4. Республика координация комитеты түбәндәге вазыйфалар башкара:

а) Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча чаралар планын формалаштыру һәм аны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген ачыклау күрсәткечләре буенча тәкъдимнәр кертә;

б) Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү эшчәнлеген координацияли;

в) Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча чаралар планын үтәүнең барышы турында еллык хисапларны карый;

г) Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрүгә бәйле башка вазыйфаларны башкара.

5. Республика координация комитеты үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Фән һәм технологияләр унъеллыгын уздыру мәсьәләләре, шулай ук Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү максатыннан Татарстан Республикасының дәүләт фәнни-техник сәясәтен гамәлгә ашыру һәм аның норматив хокукый һәм оештыру нигезләрен камилләштерү буенча Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр җибәрергә;

б) билгеләнгән тәртиптә федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, фән, мәгариф һәм башка оешмалардан, иҗтимагый берләшмәләрдән Республика координация комитеты эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмат һәм материаллар соратырга һәм алырга;

в) Республика координация комитеты вәкаләтләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча эш төркемнәре төзергә;

г) үз утырышларына федераль башкарма хакимияте органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, фән, мәгариф һәм башка оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен чакырырга һәм аларның хисапларын тыңларга;

д) Фән һәм технологияләр унъеллыгы кысаларында гамәлгә ашырыла торган чараларда һәм проектларда катнашуга коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмаларны җәлеп итү;

е) Фән һәм технологияләр унъеллыгы кысаларында гамәлгә ашырыла торган чараларны һәм проектларны финанслауга бюджеттан тыш чыганаклардан акча җәлеп итү.

6. Республика координация комитеты составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

7. Республика координация комитеты составына Республика координация комитетының рәистәшләре, секретаре һәм аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнашучы башка әгъзалары керә.

8. Республика координация комитеты рәистәшләре:

а) Республика координация комитеты эшенә җитәкчелек итә, Республика координация комитеты утырышларында каралачак мәсьәләләрне, аларны карау срокларын һәм тәртибен билгели;

б) Республика координация комитеты әгъзалары арасында вәкаләтләрне (вазыйфаларны) бүлә;

в) көн тәртибен, утырышларны үткәрү датасын, урынын һәм вакытын билгели һәм раслый;

г) Республика координация комитеты утырышлары беркетмәләренә һәм башка документларына кул куя.

9. Республика координация комитеты секретаре:

а) Республика координация комитеты утырышларында шәхсән катнаша;

б) Республика координация комитеты әгъзаларына утырышны уздыру урыны, датасы, вакыты турында кимендә биш көн алдан хәбәр итә, утырышның көн тәртибен җибәрә;

в) Республика координация комитеты утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җавап бирә.

10. Республика координация комитеты әгъзалары:

а) Республика координация комитеты утырышларында шәхсән катнаша;

б) Республика координация комитеты вәкаләтләренә керә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга куя;

в) Республика координация комитеты карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыра.

11. Республика координация комитеты утырышлары турыдан-туры яки читтән торып катнашу рәвешендә, ихтыяҗ туган саен, әмма кимендә елга бер тапкыр үткәрелә.

12. Республика координация комитеты утырышларын рәистәшләр яки аларның берсе алып бара.

13. Республика координация комитеты утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, эш алып барырга хокуклы дип санала. Республика оештыру комитеты карары, әгәр аны хуплап утырышта катнашкан әгъзаларның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Республика оештыру комитеты утырышында көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерү һәм тавыш бирү йомгаклары буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә. Республика оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәистәшләр яки аларның берсе кул куя.

14. Республика координация комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынган органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җирле үзидарә

органнарына, иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә, кызыксынган башка затларга эшчәнлек алып барганда куллану өчен җиткерелә.

15. Республика координация комитеты карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектлары эшләнергә мөмкин.

16. Республика координация комитеты эшчәнлеген техник яктан оештыруны һәм тәэмин итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «10» ноябрендәге
ПУ-796 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасында Фән һәм технологияләр унъеллыгын үткәрү буенча республика координация комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Фазлыева<br>Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Республика координация комитеты рәистәше |
| Гыйльметдинов<br>Альберт Харис улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, Республика координация комитеты рәистәше |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, Республика координация комитеты секретаре |
| Абдуллаҗанов<br>Эдвард Юныс улы | «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Әйделдинов<br>Айнур Тәүфикъ улы | «Татарстан Республикасы инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Алибаев<br>Тимур Лазо улы | «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты-КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Әхмәтова<br>Әдилә Марат кызы | «Казан талантлар ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасы башкарма директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Дьяконов<br>Александр Анатольевич | «Әлмәт дәүләт нефть институты» дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Казаков<br>Юрий Михайлович | «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Калачев<br>Алексей Алексеевич | «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Когогин<br>Сергей Анатольевич | «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Коробченко<br>Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Мәганов<br>Наил Өлфәт улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Миңнеханов<br>Рәфкать Нургали улы | Цифрлы үсешкә ярдәм итү ассоциациясе Советы рәисе (килешү буенча) |
| Нуретдинов<br>Айрат Рәфкать улы | «Таттелеком» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Ризванов<br>Ирек Асаф улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Сәлахов<br>Мәгъзүм Хәлимулла улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президенты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин<br>Диас Нургали улы | «Идея» инновация-җитештерү технопаркы» ябык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Сафин<br>Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Созинов<br>Алексей Станиславович | Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Сөләйманов<br>Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Тормасов<br>Александр Геннадьевич | «Иннополис Университеты» автоном коммерциячел булмаган югары белем бирү оешмасы ректоры (килешү буенча) |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Яруллин<br>Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |